# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**11 ноябрь 2025 ел** **№ 2**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге составына керүче Усай авылында 2026 елда үзара салым кертү турында

2025 елнын 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 маддәсе, 28.07.2004 №45-ТРЗ Татарстан Республикасы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы законының 35 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Усай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Усай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 нче төркем инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 2026 елда 700 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тору (Усай торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча машина йөртүче эшләре һәм хезмәт күрсәтүләре өчен түләү));

2) торак пункт территориясен төзекләндерү (торак пункт территориясен чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү): Усай торак пунктында трактор тоту (Беларус МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, запас частьләр, чыгым материаллары, агачларны, куакларны кисү (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

3) Усай торак пунктындагы Совет урамы буенча су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системаларын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр өчен килешү буенча түләү) су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне) тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

4) Усай торак пунктындагы урамнарны яктырту өчен светодиодлы лампалар сатып алу һәм урнаштыру.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән,Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru., Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http: //sarman.tatarstan.ru. кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә бастырып чыгарырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы Гилева Р.М.Гилева